*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2021-2022 нче уку елы)
**6 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 60 минут**
**Максималь балл – 42**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. [в] авазы кулланылган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *тау*;
   ә) *авыл*;
   б) *тавык*;
   в) *вагон*.

2. Ачык иҗектән генә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *бау*;
   ә) *су*;
   б) *таш*;
   в) *җил*.

3. Фразеологизмның мәгънәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   *чебен очканы да ишетелә*
   а) *тыныч*;
   ә) *курку*;
   б) *эшләмәү*;
   в) *үпкәләү*.

4. Омонимнардан торган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *сандугач – былбыл*;
   ә) *яшел – зәңгәр*;
   б) *карга – карга*;
   в) *күз – яз*.

5. Тезмә сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) *башваткыч*;
   ә) *үги ана яфрагы*;
   б) *хатын-кыз*;
   в) *сыйныфташ*.

6. Чыгыш килешенең кушымчаларын билгеләгез. **(2 балл)**

а) *-га/-гә, -ка/-кә*;

ә) *-ны/-не*;

б) *-дан/-дән, -тан/-тән, -нан/-нән;*

в) *-да/-дә, -та/-тә*.

7. Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**

а) *кызыл;*

ә) *кып-кызыл;*

б) *кызылрак*;

в) *кызгылт*.

8. Җәенке җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**

а) *Алсу бүген мәктәпкә бармады.*

ә) *Илнур һәм Марат – укучылар.*

б) *Агачлар үсә.*

в) *Көз.*

## II. Теоретик бирем.

Күпнокталар урынына тиешле сүзләрне өстәп языгыз. **(6 балл)**

*[у], [ү], [ө], [о] –* **.....................** *сузык авазлар. [***.........***] – тел уртасы тартыгы. Көләргә – еларга –* **.....................**. *Сүзләр туры һәм* **................** *мәгънәдә булырга мөмкин. Бәйләгеч кушымчалар сүз* **...................** *килә. Минеке, синеке, аныкы –* **.......................** *алмашлыклары.*

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(14 балл)**

*Осенью небо пасмурное. Солнце почти не выглядывает из-за туч. Дуют холодные ветры. Деревья и кусты стоят голые. Облетел их зелёный наряд. Трава пожелтела и засохла. Кругом лужи и грязь.*

2. Көзге табигать турында тагын ниләр өсти аласыз? Шул хакта 6 җөмлә төзеп языгыз. **(6 балл)**